**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2073**
**01.04.2024**

Башкарма комитетның «2015-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 7047 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015-2025 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 18 сентябрендәге 1150 номерлы Карары, шәһәр Уставының 53 статьясы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2015-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 7047 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2014 елның 8 декабрендәге 7609 номерлы, 2016 елның 30 мартындагы 1423 номерлы, 2016 елның 20 маендагы 2539 номерлы, 2018 елның 12 мартындагы 1243 номерлы 2018 елның 6 сентябрендәге 4995 номерлы, 2019 елның 29 мартындагы 1613 номерлы, 2019 елның 16 сентябрендәге 4704 номерлы, 2020 елның 13 августындагы 3930 номерлы, 2021 елны 20 февралендәге 1209 номерлы, 2021 елның 6 августындагы 5222 номерлы, 2021 елның 11 октябрендәге 6661 номерлы, 2022 елның 31 мартындагы 1716 номерлы, 2022 елның 14 июлендәге 3559 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын раслау турында»;

2) преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Россия Федерациясе Президентының «2021-2024 елларга коррупциягә каршы торуның илкүләм планы турында» 2021 елның 16 августындагы 478 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы Карары, шәһәр Уставының 53 статьясы нигезендә»;

3) 1 пунктта «2015-2025 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын финанслауны «Яшьләр сәясәте һәм балаларны сәламәтләндерү» 07.07 бүлеге буенча шәһәр бюджеты акчалары хисабына 360,00 мең сум күләмендә тәэмин итәргә, шул исәптән: 2024 ел - 120,00 мең сум, 2025 ел - 120,00 мең сум, 2026 ел - 120,00 мең сум.»;

5) «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 1 апрелендәге
2073 номерлы карарына
кушымта

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасы

1 бүлек. Муниципаль программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Муниципаль программаның исеме | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру (алга таба - программа) |
| Программаны әзерләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | 1. Россия Федерациясе Президентының «2021-2024 елларга коррупциягә каршы торуның илкүләм планы турында» 2021 елның 16 августындагы 478 номерлы Указы.<br>2. Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Законы.<br>3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы Карары.<br>4. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Шәһәр Хакиме ярдәмчесе (коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча) |
| Программаны башкаручылар | 1. Башкарма комитетның тармак (функциональ) һәм территориаль органнары.<br>2. Шәһәр Советы (килешү буенча).<br>3. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы (килешү буенча) |
| Программаның максаты | Коррупция дәрәҗәсен киметү, җирле үзидарә органнарының һәм гражданнар җәмгыяте институтларының коррупциягә каршы эшчәнлеген координацияләүнең нәтиҗәлелеген арттыру юлы белән җәмгыять тормышының һәм эшчәнлегенең барлык өлкәләрендә аның барлыкка килү сәбәпләрен бетерү |
| Программаның бурычлары | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә коррупциягә каршы тору, шул исәптән хокукый һәм оештыру инструментларын һәм механизмнарын камилләштерү.<br>Җирле үзидарә органнары тарафыннан коррупциягә каршы экспертиза үткәрү юлы белән эшләнгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларында коррупция факторларын ачыклау һәм бетерү, җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен шартлар тәэмин итү.<br>Коррупциягә каршы уку оештыру һәм коррупциягә каршы пропаганданы тәэмин итү, коррупциягә каршы көрәшкә гражданнар җәмгыятенең кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларын |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | җәлеп итү.<br>Шәһәрнең җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең гражданнар өчен ачыклыгын, файдалану мөмкинлеген тәэмин итү, гражданар җәмгыяте белән үзара хезмәттәшлек итү, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру.<br>Шәһәрнең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуны гамәлгә ашырганда ачыклыкны, намуслы конкурентлыкны һәм объективлыкны тәэмин итү | | | | |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2024-2026 еллар<br>Программа этапларга бүленми | | | | |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары (еллар буенча бүлеп) | Финанслау чыганагы | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
| | Муниципаль бюджет | 2024 | 2025 | 2026 | Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум) |
| | Республика бюджеты | 120,00 | 120,00 | 120,00 | 360,00 |
| | Федераль бюджет | | | | |
| | Башка чыганаклар | | | | |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Программаны тормышка ашыру тәэмин итә:<br>1) бюджет акчаларыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны;<br>2) коррупциягә каршы тору өлкәсендә җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрүне;<br>3) һөнәри белем бирүне һәм муниципаль хезмәткәрләрне әзерләү дәрәҗәсен күтәрүне. | | | | |
| Программаны тормышка ашыруга контрольне оештыру системасы | Башкарма комитет | | | | |

## 2 бүлек. Аңлатма язуы

Яр Чаллы шәһәрендә Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәте муниципаль дәрәҗәдә норматив хокукый актлар эшләү һәм хокук куллану эшен камилләштерү, шәһәрдә коррупциягә каршы тору чараларын активлаштыру белән характерлана. Эш коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә иҗтимагый мөнәсәбәтләрне камилләштерү һәм, федераль һәм республика дәрәҗәсендә коррупциягә каршы тору турындагы законнар үзгәрү сәбәпле, аларны үзгәртү буенча алып барылды.

Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль коррупциягә каршы программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә түбәндәге нәтиҗәләргә ирешелде:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең җәмәгатьчелек өчен мәгълүмати ачыклык дәрәҗәсе артты;

2) коррупциягә каршы нәтиҗәле көрәшү өчен кирәкле норматив-хокукый база үз вакытында формалаштырыла, шулай ук норматив хокукый актлар сыйфаты яхшырды;

3) муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри дәрәҗәсе артты;

4) билгеләнгән срокларда алдагы программаларның үтәлешенә анализ үткәрелде, аларны тормышка ашыруның арадаш йомгаклары ясалды, коррупциягә каршы тору турында законнардагы үзгәрешләрне исәпкә алып, бурычларга һәм программа чараларына төгәллек кертелде;

5) коррупциягә каршы тору нәтиҗәлелеген күтәрү, барлыкка килгән коррупция ситуациясен анализлау өчен шәһәр Хакиме ярдәмчесе (коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча) вазыйфасы кертелде.

Әмма күрсәтелгән чаралар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарында коррупция дәрәҗәсен киметү өчен җитәрлек түгел. Шуңа бәйле рәвештә, түбәндәгеләр буенча эшне дәвам итәргә кирәк:

1) шәһәрдә реаль коррупция ситуациясе, коррупциягә каршы сәясәтне тормышка ашыру буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан күрелә торган чаралар турында халыкка мәгълүмат бирү;

2) коррупциягә каршы тору һәм коррупцион хокук бозуларны кисәтү өчен шартлар тудыру;

3) җирле үзидарә органнарының гражданнар җәмгыяте белән үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү, коррупциягә каршы тору буенча иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү; коррупциягә каршы торуга юнәлдерелгән гамәлдәге хокукый, белем һәм тәрбия бирү чараларын эзлекле куллану.

## 3 бүлек. Программаның төп максатлары, бурычлары

Программаның максаты - коррупция дәрәҗәсен киметү, җирле үзидарә органнарының һәм гражданнар җәмгыяте институтларының коррупциягә каршы эшчәнлеген координацияләүнең нәтиҗәлелеген арттыру юлы белән җәмгыять тормышының һәм эшчәнлегенең барлык өлкәләрендә аның барлыкка килү сәбәпләрен бетерү.

Программаның бурычлары:

1) коррупциягә каршы тору, шул исәптән хокукый һәм оештыру инструментларын һәм механизмнарын камилләштерү;

2) коррупциягә каршы укуны һәм коррупциягә каршы пропаганданы активлаштыру, коррупциягә каршы көрәшкә гражданнар җәмгыятенең кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларын җәлеп итү;

3) муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру;

4) эшмәкәрлеккә (бизнеска) административ басымны киметү.

Муниципаль программаны тормышка ашыру срогы: 2024-2026 еллар.

Муниципаль программа этапларга бүленми.

## 4 бүлек. Программа чараларының исемлеге һәм кыскача тасвирламасы

### Программа чараларының исемлеге һәм кыскача тасвирламасы

| № т/б | Чараның исеме | Индикаторның исеме | Башкаручы | Үтәү срогы | Индикаторның үлчәү берәмлеге | Индикатор күрсәткече | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | База елы | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| Максат: коррупция дәрәҗәсен киметү, җирле үзидарә органнарының һәм гражданнар җәмгыяте институтларының коррупциягә каршы эшчәнлеген координацияләүнең нәтиҗәлелеген арттыру юлы белән җәмгыять тормышының һәм эшчәнлегенең барлык өлкәләрендә аның барлыкка килү сәбәпләрен бетерү | | | | | | | | | | | | |
| Бурыч: Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә коррупциягә каршы тору, шул исәптән хокукый һәм оештыру инструментларын һәм механизмнарын камилләштерү | | | | | | | | | | | | |
| 1. | Федераль, республика законнарын үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасында гамәлдәге коррупциягә каршы нормаларны куллану практикасын гомумиләштерү нигезендә, җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларын эшләү һәм коррупциягә каршы тору өлкәсендә җирле үзидарә органнарының гамәлдәге муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү (кирәк булганда гамәлгә ашырыла) | Җирле үзидарә органнарының федераль һәм республика законнарына туры китерелгән коррупциягә каршы тору өлкәсендә муниципаль норматив хокукый актлары өлеше | Башкарма комитет, Шәһәр Советы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 2. | Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан | Коррупциягә каршы тору буенча кабул ителгән оештыру һәм хокукый чаралар, шул исәптән кадрлар сәясәтендә эчке | Башкарма комитет, Шәһәр Советы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | бирелә торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын, федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында» 2009 елның 21 сентябрендәге 1065 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында» 2010 елның 1 ноябрендәге 711-ПУ номерлы Указы нигезендә, коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча җирле үзидарә органнары бүлекчәләренең (коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затларының) нәтиҗәле эшен тәэмин итү; | контроль һәм коррупциягә каршы механизм | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Ммуниципаль хезмәткәрләр тарафыннан функцияләрне тормышка ашырганда барлыкка килә торган коррупция куркынычларын бәяләүне үткәрү, аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә төзәтмәләр кертү (кирәк булганда) | Коррупциягә каршы тору буенча кабул ителгән оештыру һәм хокукый чаралар, шул исәптән кадрлар сәясәтендә эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизм | Шәһәр Советы (килешү буенча), Башкарма комитет, Контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 4. | Шәһәрнең коррупциягә каршы тору эшен координацияләү буенча комиссия эшенең еллык планнарын раслау һәм үтәү | Коррупциягә каршы тору буенча кабул ителгән оештыру һәм хокукый чаралар, шул исәптән кадрлар сәясәтендә эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизм | Башкарма комитет, Шәһәр Советы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 5. | Муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси делоларына анализ ясау һәм мондый хезмәткә керешкәндә тапшырыла торган анкеталардагы мәгълүматларны актуальләштерү аларның туганнары һәм кода-кодагыйлары (ир туганнарының һәм кыз туганнарының хатыннары һәм ирләре, һәм үз иренең (хатынының) ир туганнары һәм кыз туганнары турында) | Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре тарафыннан коррупциягә каршы тору өлкәсендәге законнар таләпләре үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар өлеше, елына планлаштырылган гомуми саннан | Башкарма комитет, Шәһәр Советы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | «Бердәм дәүләт юридик затлар реестры» һәм «Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестры» Федераль салым хезмәтенең мәгълүмат базаларыннан, башка мәгълүмат системаларыннан файдаланып (елга кимендә бер тапкыр), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт турында законнарда каралган чикләүләр һәм тыюлар үтәлешен, шул исәптән эшмәкәрлек эшчәнлегендә катнашу предметына тикшерүне үткәрү | Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре тарафыннан коррупциягә каршы тору өлкәсендәге законнар таләпләре үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар өлеше, елына планлаштырылган гомуми саннан | Башкарма комитет, Шәһәр Советы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 7. | Муниципаль вазыйфаларны, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашуына мониторинг үткәрү | Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре тарафыннан коррупциягә каршы тору өлкәсендәге законнар таләпләре үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар өлеше, елына планлаштырылган гомуми саннан | Шәһәр Советы (килешү буенча), Башкарма комитет, Контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 8. | «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясы нигезләмәләрендә каралган чараларны күрү бурычы | Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре тарафыннан коррупциягә каршы тору өлкәсендәге законнар таләпләре | Башкарма комитет, Шәһәр Советы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | үтәлешен тәэмин итү максатларында, җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар белән коррупцияне кисәтү буенча, шул исәптән оешмалар тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын ачыклау, булдырмау һәм җайга салу буенча эш алып бару | үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар өлеше, елына планлаштырылган гомуми саннан | | | | | | | | | | |
| 9. | Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюлар, чикләүләр һәм таләпләр үтәлмәгән һәр очракта, законнарда каралган юридик җаваплылык чараларын куллануга контрольне гамәлгә ашыру | Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре тарафыннан коррупциягә каршы тору өлкәсендәге законнар таләпләре үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар өлеше, елына планлаштырылган гомуми саннан | Башкарма комитет, Шәһәр Советы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 10. | Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турында законнарының мәнфәгатьләр конфликтын булдырмауга һәм җайга салуга, шул исәптән аларны үтәмәгән очракта мондый затларны җаваплылыкка тартуга кагылышлы таләпләре үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыру | Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре тарафыннан коррупциягә каршы тору өлкәсендәге законнар таләпләре үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар өлеше, елына планлаштырылган гомуми саннан | Башкарма комитет, Шәһәр Советы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Бурыч: шәһәрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан коррупциягә каршы экспертиза үткәрү юлы белән эшләнгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларында коррупция факторларын ачыклау һәм бетерү, җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен шартлар тәэмин итү | | | | | | | | | | | | |
| 11. | Җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен шартлар тәэмин итү һәм күрсәтелгән экспертизаны үткәрү нәтиҗәләрен гомумиләштерү | Җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизага дучар ителгән өлеше | Башкарма комитет, Шәһәр Советы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 12. | Җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларын норматив хокукый актлар проектларын әзерләү һәм алар буенча иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны урнаштыру өчен булдырылган рәсми сайтта http://tatarstan.ru/regulation урнаштыру | Җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизага дучар ителгән өлеше | Башкарма комитет, Шәһәр Советы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| Бурыч: коррупциягә каршы уку оештыру һәм коррупциягә каршы пропаганданы гамәлгә ашыру, коррупциягә каршы көрәшкә гражданнар җәмгыятенең кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларын җәлеп итү | | | | | | | | | | | | |
| 13. | Коррупция факторларына һәм максатчан төркемнәр арасында тормышка ашырыла торган коррупциягә каршы чараларга тармак тикшеренүләре үткәрү. Алынган нәтиҗәләрне коррупциягә каршы тору буенча беренчел чараларны эшләү өчен куллану | Үткәрелгән тикшеренүләр саны | Башкарма комитет, Шәһәр Советы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 30 | 30 | 30 | 30 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 14. | Әлеге эшкә коррупциягә каршы торуда катнашучы иҗтимагый советларны, иҗтимагый берләшмәләрне һәм гражданнар җәмгыятенең башка институтларын җәлеп итеп, җирле үзидарә органнары һәм муниципаль оешмалар хезмәткәрләрендә коррупциягә карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру, шул исәптән чикләүләрне, тыюларны үтәү, шулай ук коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәү буенча оештыру, аңлату һәм башка чаралар күрү буенча эшне гамәлгә ашыру | Коррупциягә каршы чаралар үткәрелгән җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең өлеше | Башкарма комитет, Шәһәр Советы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 50 | 50 | 50 | 50 | - | - | - |
| 15. | Башкарма комитет карамагындагы иҗтимагый совет утырышларында коррупциягә каршы тору программаларын тормышка ашыру турында хисапларны карап тикшерү | Коррупциягә каршы чаралар үткәрелгән җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең өлеше | Башкарма комитет, Шәһәр Советы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 50 | 50 | 50 | 50 | - | - | - |
| 16. | Белем бирү программаларына коррупциягә каршы тематика буенча дисциплиналар кертеп, муниципаль хезмәткәрләрне квалификация күтәрү программалары буенча укыту | Коррупциягә каршы тематика буенча дисциплиналар кертелгән программалар буенча квалификация күтәргән муниципаль хезмәткәрләр өлеше | Башкарма комитет, Шәһәр Советы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 33 | 33 | 33 | 33 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 17. | Һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларының студентлары арасында коррупциягә каршы «Намуслылар буыны» тематикасына эшләрнең шәһәр конкурсын оештыру | Коррупциягә карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру | Башкарма комитет, «Нур» МҮ» МАУ (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | катнашучылар саны | 30 | 30 | 30 | 30 | 25,00 | 25,00 | 25,00 |
| 18. | «Тикшерү алып барыла» интеллектуаль-мәгълүмати квесты оештыру | Коррупциягә карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру | Башкарма комитет, «Нур» МҮ» МАУ (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | катнашучылар саны | 70 | 70 | 70 | 70 | 28,00 | 28,00 | 28,00 |
| 19. | «Коррупциягә юк дип әйт!» белем-танып белү квесты оештыру | Коррупциягә карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру | Башкарма комитет, «Нур» МҮ» МАУ (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | катнашучылар саны | 250 | 250 | 250 | 250 | 35,00 | 35,00 | 35,00 |
| 20. | «Гадел белемнәр» коррупциягә каршы интеллектуаль-танып белү уены оештыру | Коррупциягә карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру | Башкарма комитет, «Нур» МҮ» МАУ (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | катнашучылар саны | 80 | 80 | 80 | 80 | 32,00 | 32,00 | 32,00 |
| Бурыч: шәһәрнең җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең гражданнар өчен ачыклыгын, файдалану мөмкинлеген тәэмин итү, гражданар җәмгыяте белән үзара хезмәттәшлек итү, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру | | | | | | | | | | | | |
| 21. | Җирле үзидарә органнарында ышаныч телефоннары, кайнар линияләр, интернет-кабул итү бүлмәләре, гражданнарга коррупциянең мәгълүм фактлары, аларны башкаруга ярдәм итүче сәбәпләр һәм шартлар турында хәбәр итәргә мөмкинлек бирә торган башка мәгълүмат каналлары эшчәнлеген тәэмин итү | Җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең гражданнар өчен ачыклыгын, файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, гражданар җәмгыяте белән үзара хезмәттәшлек итү, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыруга юнәлдерелгән чараларның үткәрелгән өлеше, елына планлаштырылган гомуми саннан | Башкарма комитет, Шәһәр Советы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 22. | Квартал саен гомумиләштереп һәм шәһәрнең коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясе утырышларында аның нәтиҗәләрен карап тикшереп, массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырылган һәм гражданнардан һәм юридик затлардан керә торган мөрәҗәгатьләрдә булган шәһәрнең вазыйфаи затлары эшчәнлегендә коррупцион чагылышлар турында мәгълүмат мониторингы үткәрү | Шәһәрнең җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең гражданнар өчен ачыклыгын, файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, гражданар җәмгыяте белән үзара хезмәттәшлек итү, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыруга юнәлдерелгән чараларның үткәрелгән өлеше, елына планлаштырылган гомуми саннан | Башкарма комитет, Шәһәр Советы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 23. | Мәгълүмат стендларын, шәһәр рәсми сайтының «Коррупциягә каршы тору» бүлеген һәм коррупциягә каршы эчтәлектәге мәгълүмат бирүнең башка формаларын рәсмиләштерү һәм актуальләштерү | Җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең гражданнар өчен ачыклыгын, файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, гражданар җәмгыяте белән үзара хезмәттәшлек итү, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыруга юнәлдерелгән чараларның үткәрелгән өлеше, елына планлаштырылган гомуми саннан | Башкарма комитет, Шәһәр Советы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 24. | Тормыш эшчәнлегенең социаль-икътисадый тармакларында коррупция чагылышлары турында гражданнар мөрәҗәгатьләренә мониторинг үткәрү | Җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең гражданнар өчен ачыклыгын, файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, гражданар җәмгыяте белән үзара хезмәттәшлек итү, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыруга юнәлдерелгән чараларның үткәрелгән өлеше, елына планлаштырылган гомуми саннан | Башкарма комитет, Шәһәр Советы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| Бурыч: шәһәрнең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуны гамәлгә ашырганда ачыклыкны, намуслы конкурентлыкны һәм объективлыкны тәэмин итү | | | | | | | | | | | | |
| 25. | Муниципаль ихтыяҗлар товарларын (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) сатып алуны гамәлгә ашырганда коррупция дәрәҗәсен киметүгә ярдәм итә торган чараларны тормышка ашыру, шул исәптән гамәлгә ашырыла торган сатып алуларның ачыклыгын һәм алардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар үткәрү, шулай ук сатып алуларда | Аларны үткәрү барышында контроль органнары тарафыннан сатып алу объектын тасвирлау кагыйдәләрен һәм контрактның башлангыч максималь бәясен формалаштыру кагыйдәләрен бозган өчен җирле үзидарә органнары вазыйфаи затын | Башкарма комитет, Шәһәр Советы (килешү буенча) | 2024-2026 еллар | шартлы берәмлекләр | 0 | 0 | 0 | 0 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | катнашучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру | административ җаваплылыкка тарту турында карар чыгарылган сатып алулар өлеше[1] | | | | | | | | | | |

[1]Күрсәткечнең зурлыгы ≤ 30 билгесе белән.

## 5 бүлек. Программа нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелегенең төп индикаторлары | Төп чараларны үтәү сроклары | 2024 | 2025 | 2026 |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Яр Чаллы шәһәрендә коррупция дәрәҗәсе (Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайты аша социологик сораштыру үткәрү аша алынган мәгълүматлар буенча/Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг Комитеты), % | ел саен | 35 | 35 | 35 |
| Коррупция күренешләренә юлыккан гражданнарның һәм оешмаларның тикшерү нәтиҗәсендә хокук бозулар ачыкланган мөрәҗәгатьләре өлеше, мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан, % | ел саен | 2 | 2 | 2 |

## 6 бүлек. Программаны тормышка ашыру механизмы

1. Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Хаким ярдәмчесе программаны тормышка ашыруны планлаштыру һәм мониторинглау функцияләрен гамәлгә ашыра.

2. Башкарма комитетның тармак (функциональ) һәм территориаль органнары:

1) программа чараларын планлаштыруны, үтәлешен оештыруны һәм аларны тормышка ашыруга контрольне гамәлгә ашыралар;

2) программа чаралары үтәлешен билгеләнгән срокларда тәэмин итәләр;

3) квартал саен хисап кварталыннан соң килүче 5 числога кадәр программа чараларын тормышка ашыру нәтиҗәләрен шәһәр Хакиме ярдәмчесенә (коррупциягә каршы тору мәсьәләсе буенча) тапшыралар;

4) максатчан индикаторларның һәм күрсәткечләрнең зурлыклары, программаны һәм аерым программа чараларын тормышка ашыру нәтиҗәләре турында мәгълүматның ачык булуын (ачыклыгын) тәэмин итәләр.

3. Программаның нәтиҗәлелеген анализлау Башкарма комитетның 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
башлыгы вазыйфаларын башкаручы Л.Р. Абдуллина